**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КҮГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**3 нче октябрь 2016 ел** **№ 73**

Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

12.06.2002 Федераль законның 15 статьясы нигезендә № 67-ФЗ “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында”, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Зеленодольск муниципаль районы “Күгеш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 10 һәм 83 статьялары," Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, Күгеш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 30 сентябрендәге 9 номерлы «Җирле референдумны үткәрү инициативасы турында» гы карары, Күгеш авыл җирлеге Советының 2016 елның 30 сентябрендәге 71 номерлы “Җирле референдумны үткәрү инициативасы турында» гы карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. 2016 елның 20 ноябренә Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2017 елда Күгеш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә һәм алган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

1. авыл җирлеге чикләрендә автомобиль юлларын төзү, ремонтлау һәм карап тоту, инерт материаллары сатып алу;
2. иректе янгын сагы һәм махсус техника эчтәлеге, шул исәптән ягулык-майлау материаллары сатып алу,
3. янгын депосы бинасын ремонтлау;
4. смета документларын әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru Күгеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында Күгеш авылы, Советская урамы, 11 йорт, (Күгеш авыл җирлегенең административ бинасы), Күгеш авылы, Советская урамы, 17 йорт (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча халыкка җиткерергә.

**Күгеш авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.А.Гатауллин**